КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 июль г.Казань № 638

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының тәгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджет акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки федераль милектәге капиталь төзелеш объектларының тәгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2021 елның 7 сентябрендәге 1517 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының тәгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен (алга таба – Кагыйдәләр) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле бюджет акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларының тәгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән

чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслаганда Кагыйдәләр нигезләмәләренә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 11 февраль, 91 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын һәм (яки) төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына чыгымнарны исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 11 февраль, 91 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 11 февраль, 91 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 1 февраль, 42 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 5 июль, 638 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар (алга таба – исәптән чыгару турында карар) кабул итү тәртибен билгели.

2. Исәптән чыгару турында карар түбәндәгеләргә карата кабул ителә:

а) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы милке хокуклары рәсмиләштерелгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларына (алга таба – төгәлләнмәгән төзелеш объектлары);

б) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән чыгымнарга (проект һәм (яки) тикшеренү эшләренә чыгымнарны кертеп) (алга таба – ясалган чыгымнар).

3. Төгәлләнмәгән төзелеш объектларын исәптән чыгару турындагы карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

а) төгәлләнмәгән төзелеш объектын хосусыйлаштыру өчен хосусыйлаштыру турында Россия Федерациясе законнарында каралган нигезләр булмау;

б) чикләрендә төгәлләнмәгән төзелеш объекты урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының төгәлләнмәгән төзелеш объектын түләүсез кабул итүдән баш тарту.

4. Ясалган чыгымнарны исәптән чыгару турында карар түбәндәге нигезләр булганда кабул ителә:

а) акча проект документациясе расланмаган яки биш елдан күбрәк элек расланган, әмма бертип проект документациясе реестрына кертелмәгән яки кабат файдаланыла торган икътисади нәтиҗәле проект документациясе дип танылмаган проект һәм (яки) тикшеренү эшләренә кертелү;

б) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында чыгымнар ясалган, төгәлләнмәгән төзелеш объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында каралган нигезләр булмау.

5. Исәптән чыгару турында карар түбәндәге формада кабул ителә:

а) әгәр төгәлләнмәгән төзелеш объектын төзү чыгымнары яки ясалган чыгымнар күләме 100 млн.сум һәм аннан күбрәк тәшкил итсә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый акты;

б) әгәр төгәлләнмәгән төзелеш объектын төзү чыгымнары яки ясалган чыгымнар күләме 100 млн.сум кимрәк булса, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы) хокукый акты.

6. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын исәптән чыгару турындагы карарда түбәндәге мәгълүматлар бирелергә тиеш:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының исеме;

б) төгәлләнмәгән төзелеш объектының исеме, шулай ук аның урнашу урыны, кадастр номеры һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге реестр номеры;

в) төгәлләнмәгән төзелеш объектын сүтү һәм (яки) төзелеш калдыкларын утильләштерү һәм төгәлләнмәгән төзелеш объекты урнашкан җир кишәрлеген рекультивацияләү кирәклеге турында булган һәм әлеге чараларны гамәлгә ашыру сроклары һәм алар өчен кирәкле акча күләменең исәп-хисабы күрсәтелгән карар һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин итү гамәлгә ашырылган капитал салуларны башкару турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карар (мондый карар булганда).

7. Ясалган чыгымнарны исәптән чыгару турындагы карарда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының исеме;

б) бухгалтерлык исәбендә ясалган капитал салулар исәпкә алынган юридик затның исеме;

в) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ясалган чыгымнарның күләмен бүлеп, ясалган чыгымнарның гомуми күләме һәм аларның төрләр (проект һәм (яки) тикшеренү эшләре, төзелеш-монтаж эшләре, капиталь төзелеш объектын төзү сметасына кертелгән җиһаз сатып алу) буенча бүленеше (мондый мәгълүмат булганда);

г) чыгымнар ясалган чор.

8. Алга таба чыгымнарны гамәлгә ашыру, төгәлләнмәгән төзелеш объектын төзү мөмкинлеге булмауның һәм (яки) максатка ярашлы булмауның нигезләве бирелгән аңлатма материаллар, шулай ук кабул ителә торган карарның финанс-икътисадый нигезләве белән исәптән чыгару турында карар проекты Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан әзерләнә һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче вәкаләтләре гамәлгә ашырылмаган очракта), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (транспорт инфраструктурасы өлкәсендә төгәлләнмәгән төзелеш объектлары һәм ясалган чыгымнар буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына килештерүгә җибәрелә. Исәптән чыгару турында карар проектын килештерү срогы карар проекты кергән көннән 14 календарь көннән артмаска тиеш, әлеге срок эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте

башкарма органнарының җаваплары булмаган очракта, исәптән чыгару турында карар проекты килештерелгән дип санала.

9. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын исәптән чыгару турында карар проектына теркәлә торган аңлатма материалларда түбәндәге мәгълүматлар һәм документлар булырга тиеш:

а) төгәлләнмәгән төзелеш объектының исеме;

б) төгәлләнмәгән төзелеш объектының инвентарь (исәпкә алу) номеры (булганда);

в) төгәлләнмәгән төзелеш объектының кадастр номеры;

г) төгәлләнмәгән төзелеш объекты төзелә башлаган ел;

д) күчемсез мөлкәт объектын исәптән чыгару турында карар кабул ителгән көнгә төгәлләнмәгән төзелеш объектының баланс кыйммәте;

е) төгәлләнмәгән төзелеш объектының кадастр кыйммәте;

ж) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата күчемсез мөлкәт объекты турында бирелгән өземтә;

з) Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата күчемсез мөлкәт объекты турында бирелгән өземтә;

и) төгәлләнмәгән төзелеш объекты урнашкан җир кишәрлеге турында мәгълүмат.

10. Ясалган чыгымнарны исәптән чыгару турында карар проектына теркәлә торган аңлатма материалларда түбәндәге мәгълүматлар һәм документлар булырга тиеш:

а) чыгымнар ясалган объектның исеме;

б) башлангыч исәпкә алу документлары булганда капиталь төзелештә эшләрне исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документациясе (башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар (КС-2), башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның кыйммәте турында белешмә кәгазьләре, кабул итү комиссиясе тарафыннан төзелеше төгәлләнгән объектны кабул итү акты (КС-14), ТОРГ-12 номерлы форма буенча товар накладнойлары, башка документлар);

в) ясалган чыгымнарның күләме;

г) ясалган чыгымнар гамәлгә ашырыла башланган ел.

11. Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары түбәндәге нигезләрнең берсе генә булган очракта да исәптән чыгару турында карар проектын килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә:

а) бу Кагыйдәләрнең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр булмау;

б) бу Кагыйдәләрнең 9 яки 10 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар һәм (яки) документлар булмау;

в) бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки ясалган чыгымнар нәтиҗәләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәре булу.

12. Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан бу Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» пунктчасында каралган нигез буенча исәптән чыгару турында карар проектын килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә, Татарстан Республикасы

дәүләт хакимияте башкарма органы мондый нигезне бетерә һәм исәптән чыгару турындагы карар проектын бу Кагыйдәләрдә каралган тәртиптә килештерүгә кабат җибәрә.

13. Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан исәптән чыгару турында карар проекты килештерелгәннән соң, бу Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы «а» пунктчасында каралган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый акты проекты, бу Кагыйдәләрнең 6 һәм 9 яки 7 һәм 10 пунктларында каралган мәгълүматлар һәм документлар теркәлеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә, ә бу Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы «б» пунктчасында каралган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан тиешле хокукый акт кабул ителә.

14. Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының берсе тарафыннан, бу Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы «а» пунктчасында каралган очракта, бу Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «в» пунктчасында каралган нигез буенча исәптән чыгару турында карар проектын килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан әлеге карар кабул ителгән көннән 30 календарь көн эчендә, тиешле чараларны гамәлгә ашыру сроклары күрсәтелеп, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки ясалган чыгымнар нәтиҗәләрен алга таба файдалану чаралары планы (алга таба – чаралар планы) әзерләнә һәм карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

15. Бу Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган чаралар планын тормышка ашыру мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле акты проекты теркәлеп һәм барлыкка килгән хәлләр аңлатылып, төгәлләнмәгән төзелеш объектын исәптән чыгару яки ясалган чыгымнар турында тәкъдим җибәрелә.

16. Бу Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының берсе тарафыннан, бу Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы «б» пунктчасында каралган очракта, бу Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «в» пунктчасында каралган нигез буенча исәптән чыгару турында карар проектын килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан әлеге карар кабул ителгән көннән 30 календарь көн эчендә, тиешле чараларны гамәлгә ашыру сроклары күрсәтелеп, чаралар планы әзерләнә һәм раслана.

17. Бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән чаралар планын тормышка ашыру мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан бу Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы «б» пунктчасында каралган исәптән чыгару турында карар кабул ителә.

18. Бу Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган чаралар планын һәм бу Кагыйдә-

ләрнең 16 пунктында күрсәтелгән чаралар планын тормышка ашыру мөмкинлеге булмау критерийлары:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан чаралар планын үз вакытында тормышка ашыруны тәэмин итү өчен барлык кирәкле һәм җитәрлек чаралар күрелү шарты белән, чаралар планын тормышка ашыру срогын башта ук билгеләнгән срок белән чагыштырганда ике тапкырдан күбрәк арттыруга китерә торган итеп, чаралар планын тормышка ашыруның башта ук билгеләнгән план срогын ике тапкырдан күбрәк күчерү (күрелгән чараларны раслау документлары булганда);

чаралар планын тормышка ашыруның план срогы чыкканнан соң чаралар планының 80 проценттан артыграк чаралары (вакыйгалары) фактта үтәлмәү (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан аны үз вакытында тормышка ашыруны тәэмин итү өчен барлык кирәкле һәм җитәрлек чаралар күрүне раслый торган документлар булганда).

________________________________